МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан шәһәре

02.02.2026 № под-149/26

Төп гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибен һәм урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 маддәсенең 5 өлеше һәм «Урта һөнәри белем алу мөмкинлеген киңәйтү буенча эксперимент үткәрү турында» 2025 елның 1 апрелендәге 40- ФЗ номерлы Федераль законының 3нче матдәсенең 1,2 өлешләре нигезендә боерам:

1. Кушымтаны расларга:

Төп гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибе;

Урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

2015 елның 27 февралендәге 1156/15 номерлы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем алу яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибен раслау турында»;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 27 февралендәге 1156/15 номерлы боерыгы белән расланган «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем алу яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибен раслау» турындагы боерыкка Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 12 мартындагы под-334/21 номерлы боерыгында кертелгән үзгәрешләр белән «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем алу яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»;

2015 елның 27 февралендәге 1156/15 номерлы «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле төп гомуми һәм урта гомуми белем алу яисә профильле укыту өчен Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибен раслау турындагы боерыкка 2022 елның 26 декабрендәге под- 2293/22 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән үзгәрешләр кертү турында».

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү һәм укучыларны йомгаклау аттестацияләве бүлегенә боерыкка кул куелган көннән алып өч эш көне эчендә аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары М.З. Закировага йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
02.02.2026
№ под-149/26
боерыгы белән расланды

# Төп гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип, төп гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы (алга таба – белем бирү оешмасы (оешмалары) аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә, укучыларны шәхси сайлап алуны (алга таба – шәхси сайлап алу) оештыруны җайга сайла.

1.2. Шәхси сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелә:

төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче яки башлангыч мәктәпнең гомуми белем бирү программасын үзләштерүне тәмамлаган укучыларны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә;

балигъ булмаган укучыларны, хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә әзерләү максаты белән «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган өстәмә гомуми белем бирү программалары белән интеграцияләнгән белем бирү программалары буенча укытуны да кертеп, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул иткәндә.

1.3. Шәхси сайлап алганда, белем бирү оешмалары, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гражданнарның белем алуга хокукларын үтәргә, кабул итү комиссияләре эшендә хәбәрдарлык һәм ачыклык шартларын булдырырга, укучыларның сәләтен һәм хирыслыгын бәяләүнең объективлыгын тәэмин итәргә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә субъектларның шәхси мәгълүмат хокукларын үтәргә тиеш.

1.4. Белем бирү оешмаларында аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары ачу һәм аларның тулылануы турында карар (күрсәтмә акт) белем бирү оешмасы һәм белем бирү өлкәсендә идарә итә торган гамәлгә куючысы белән үзара килешеп кабул ителә. Бу карар, агымдагы уку елының 1 мартыннан да соңга калмыйча кабул ителә һәм 10 календарь көненнән дә соңга калмыйча, белем бирү оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, белем бирү оешмасының мәгълүмат

стендларында урнаштырыла. Укучыларга һәм балигъ булмаган укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә), әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш, башка ысуллар белән җиткерелә.

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары белем бирү оешмасы мөмкинлекләрен, укучыларның, балигъ булмаган укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) мәнфәгатьләрен һәм белем алу ихтыяҗларын исәпкә алып ачыла.

Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү оешмаларында аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары ачу турында карар, югары белем бирә торган тиешле белем бирү оешмалары тарафыннан, законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

## II. Шәхси сайлап алуны оештыру тәртибе

2.1. Шәхси сайлап алуны оештыру белем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, әлеге Тәртип һәм белем бирү оешмасының локаль норматив акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Гаризаларны тапшыру сроклары, вакыты, урыны һәм укучыларны шәхси сайлап алу сроклары һәм процедурасы, аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерү нигезендә өйрәнелә торган фәннәр турында мәгълүмат, белем бирү оешмасының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, белем бирү оешмасының мәгълүмат стендларында урнаштырыла һәм укучыларга, балигъ булмаган укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) шәхси сайлап алу башланырга 45 көннән дә соңга калмый башка ысуллар белән җиткерелә.

2.3. Шәхси сайлап алу:

яңа уку елында төп гомуми белем алу өчен, бер белем бирү оешмасы эчендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә, агымдагы  уку елының 27 маеннан 27 июненә кадәр үткәрелә;

яңа уку елында төп гомуми белем алу өчен, бер белем бирү оешмасыннан икенче белем бирү оешмасындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә, кабул итүче белем бирү оешмасы укучыны яңа уку елының 1 сентябреннән үзенә кабул итү өчен, агымдагы уку елының 27 маеннан 27 июненә кадәр үткәрелә.

Әгәр шәхси сайлап алуның беренче көне эш көне булмаган көнгә туры килсә, шәхси сайлап алуның башлану көне дип аннан соңгы эш көне санала.

Шулай ук, төп гомуми белем алу өчен укучыларны шәхси сайлап алу уку елы дәвамында да аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларында буш урыннар булганда (барлыкка килгәндә) үткәрелә.

Төп гомуми белем бирү программасын үзләштерү вакыты кысаларында «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган бер дәүләт гомуми

белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчергәндә шәхси сайлап алу уздырылмый.

2.4. Шәхси сайлап алуда катнашу турында гаризаны (алга таба – гариза) карау срогы – гариза тапшырылган көннән алып 30 календарь көнен тәшкил итә.

2.5. Укучыларны шәхси сайлап алу, аларның уку елындагы казанышларын исәпкә алып, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүгә сәләтләрен бәяләү нигезендә, әлеге Тәртиптә билгеләнгән система һәм укучыларның аерым фәннәрне өйрәнүгә сәләтләрен бәяләү критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Белем бирү оешмалары, укучыларны шәхси сайлап алуны, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары өчен рейтинг балларын санау юлы белән формалаштырылган укучылар рейтингы нигезендә уздыралар:

соңгы уку елы өчен барлык фәннәр буенча еллык билгеләрнең уртача баллары;

төп гомуми белем бирү программасы буенча укыган елларында укучыларның бөтенроссия олимпиадасында яуланган призлы урыннары;

тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясенең Фән һәм югары белем министрлыгы боерыклары белән расланган олимпиадаларда укучыларның яуланган призлы урыннары.

тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларда, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрне үстерүгә, фәнни (фәнни-тикшеренү), инженер-техник, уйлап табу, иҗади, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуны үстерүгә юнәлтелгән чараларда укучыларның яулаган призлы урыннары.

Шәхси сайлап алуны оештырганда укырга керү сынауларын имтиханнар рәвешендә уздыру рөхсәт ителми.

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары ачу турында карар кабул иткән төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү оешмалары тарафаннын шәхси сайлап алу уздырылганда, белем бирү оешмасы гамәлгә ашыра торган белем бирү программасының, тирәнтен дәрәҗәдә өйрәнелә торган фәннәрнең юнәлешен исәпкә алып, шәхси сайлап алу критерийлары гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә. Гамәлгә куючы тарафыннан критерийлар билгеләнмәгән очракта, алар күрсәтелгән белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

2.7. Укучылар рейтингы түбәндәге критерийлар нигезендә, укучыларның шәхси казанышлары өчен бирелгән нәтиҗәләр буенча, баллар суммасын санау юлы белән формалаштырыла:

Р балл = К1+К2+К3+К4+К5+К6:

Р балл- аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфлары өчен укучының рейтинг баллы, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

К1 - соңгы уку елы өчен барлык предметлар буенча еллык билгеләрнең уртача баллары;

К2 - тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, тирәнтен өйрәнүле фәннәрдән тыш, укучыларның бөтенроссия олимпиадасының аерым этапларында яуланган призлы урыннары;

К3- тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, тирәнтен өйрәнүле фәннәр буенча, укучыларның бөтенроссия олимпиадасының аерым этапларында яуланган призлы урыннары;

К4 - тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, тирәнтен өйрәнүле фәннәрдән тыш, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясенең Фән һәм югары белем министрлыгы боерыклары белән расланган олимпиадаларда укучыларның яуланган призлы урыннары;

К5 - тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, тирәнтен өйрәнүле фәннәр буенча, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларда, чараларда укучыларның яулаган призлы урыннары.

К6 - ике укырга керү сынавы нәтиҗәләре буенча уртача балл (алар уздырылган очракта).

Төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына Р баллны билгеләү өчен күрсәткеч кыйммәтләре

| Күрсәт-кеч | Олимпиада-ның мәктәп этабы (баллар саны) | Олимпиаданың муниципаль этабы (баллар саны) | Олимпиаданың, башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларның, чараларның төбәк/сайлап алу этабы (баллар саны) | Олимпиаданың, башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларның, чараларның йомгаклау этабы (баллар саны) |
|---|---|---|---|---|
| К2 | 1 балл (нинди дә булса статус) | 2 балл (призер статусы) 3 балл (җиңүче статусы) | 3 балл (призер статусы) 4 балл (җиңүче статусы) | 4 балл (призер статусы) 5 балл (җиңүче статусы) |
| К3 | 1 балл (призер статусы) 2 балл (җиңүче статусы) | 4 балл (призер статусы) 6 балл (җиңүче статусы) | 6 балл (призер статусы) 8 балл (җиңүче статусы) | 8 балл (призер статусы) 10 балл (җиңүче статусы) |
| К4 | | | 6 балл (призер | 12 балл (призер |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | статусы)<br>7 балл (җиңүче статусы) | статусы)<br>13 балл (җиңүче статусы) |
| К5 | | | 12 балл (призер статусы)<br>13 балл (җиңүче статусы) | 24 балл (призер статусы)<br>25 балл (җиңүче статусы) |

Белем бирү оешмасы, шәхси сайлап алуны уздырганда, өстәмә рәвештә, икедән артык булмаган бәяләү эшләре (яисә бер бәяләү эше һәм әңгәмә) формасында укырга керү сынавын оештырырга мөмкин.

Бәяләү эшләренең, шулай ук әңгәмәләрнең формасы һәм эчтәлеге, аларны үткәрү тәртибе һәм шәхси сайлап алуны уздырганда нәтиҗәләрне исәпкә алу белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнә.

Шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча кабул итү яки күчерү хокукына, һәр катнашучының җыйган суммар баллын кимү тәртибендә күрсәтеп, иң югары рейтинглы укучылар ия була.

2.8. Укучыларның түбәндәге категорияләре, шәхси сайлап алуның нәтиҗәләре тигез булган очракта, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына кабул иткәндә өстенлекле кабул ителү хокукына ия:

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы (алга таба – 458 номерлы Тәртип) белән расланган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү Тәртибендә билгеләнгән хокукка ия укучылар;

белем бирү оешмаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен белем алуның кирәкле махсус шартлары булган очракта, психолог-медицина-педагогик комиссия һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәләре нигезендә тиешле мәгариф оешмаларында белем алуга каршы килүләре булмаган сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар, инвалид балалар;

күрсәтелгән белем бирү оешмасына беркетелгән территориядә яшәүче укучылар;

федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардагы башка затлар.

2.9. Укучыларның түбәндәге категорияләре, шәхси сайлап алуның нәтиҗәләре тигез булган очракта, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына кабул ителгәндә өстенлекле кабул ителү хокукына ия:

458 нче Тәртиптә билгеләнгән әлеге хокукка ия булган укучылар;

махсус хәрби операция яисә террорчылыкка каршы операция уздырыла торган районнардан эвакуацияләнгән балалар;

федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардагы башка затлар.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 86 маддәсенең 6[1] өлешендә күрсәтелгән балаларны «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү укырга керү сынауларысыз һәм рейтинг балларын анализламыйча гамәлгә ашырыла.

2.10. Белем бирү оешмасы үзенең сайтында һәм мәгълүмат стендында, локаль норматив актта билгеләнгән срокта, шәхси сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштыра, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

шәхси сайлап алуны уздыру сроклары;

гаризаларны кабул итә башлау һәм аларны кабул итүнең тәмамлану датасы, вакыты;

гаризаларны кабул итү урыны;

гариза тапшыру формасы һәм ысуллары;

шәхси сайлап алуда катнашу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

тирәнтен укыту оештырыла торган фәннәр;

шәхси сайлап алуны уздыру формалары һәм шәхси сайлап алу критерийлары;

укучыларга, ата-ана(лар)га (законлы вәкил(ләр)гә) шәхси сайлап алу йомгаклары турында мәгълүмат бирү формалары, сроклары һәм ысуллары;

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта апелляцияләр бирү тәртибе һәм сроклары.

2.11. Шәхси сайлап алуда катнашыр өчен балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) агымдагы елның 26 маен да кертеп белем бирү оешмасына гариза бирәләр һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2023 елның 6 апрелендәге 240 номерлы боерыгы белән расланган тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны башка оешмаларга күчерүне гамәлгә ашыру Тәртибе һәм шартларында билгеләнгән яисә 458 Тәртиптә билгеләнгән документларга өстәп түбәндәге документларны тапшыралар:

соңгы уку елы өчен укыту планына кертелгән барлык фәннәрдән еллык билгеләр ведомосте. Әлеге ведомость тиешле белем бирү оешмасының җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән таныкланырга тиеш.

бөтенроссия укучылар олимпиадасының барлык этапларында җиңүче һәм (яисә) призер грамоталары, дипломнары күчермәләре (булган очракта);

исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән

расланган укучылар олимпиадаларының сайлап алу һәм (яисә) йомгаклау этапларында җиңүче һәм (яисә) призер грамоталары, дипломнары, сертификатлары, таныклыклары күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 2.8 һәм 2.9 пунктларында күрсәтелгән белем бирү оешмасына кабул иткәндә өстенлек хокукы булуын раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта).

Әгәр шәхси сайлап алуда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогының соңгы көне ял көненә туры килсә, срок тәмамлану көне дип алдагы эш көне санала.

2.12. Гаризаны балигъ булган укучылар яисә балигъ булмаган укучыларның ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкил(ләр)е) әлеге Тәртипнең 2.11 пунктының беренче абзацында билгеләнгән форма буенча һәм срокларда тапшыралар.

Гаризада түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

б) укучының туу датасы;

в) укучының яшәү урыны адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;

г) балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарның) (законлы вәкил(ләр)енең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

д) балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарның) (законлы вәкил(ләр)енең) яшәү урынының адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;

е) балигъ булган укучының яисә балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарының) (законлы вәкил(ләр)енең) электрон почтасы адрес(лар)ы (булган очракта), телефон номер(лар)ы (булган очракта);

ж) әлеге Тәртипнең 2.8 һәм 2.9 пунктларында күрсәтелгән белем бирү оешмасына кабул иткәндә өстенлек хокукы булу;

з) белем бирү теле (Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телдә яисә чит телдә белем алган очракта);

и) Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган тел (Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен өйрәнүгә хокукны гамәлгә ашырган очракта);

к) Россия Федерациясе территориясенә керүче республиканың дәүләт теле (белем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе территориясенә керүче республиканың дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге бирелгән очракта);

л) балигъ булган укучыны, балигъ булмаган укучының ата-анасын (ата-аналарын) (законлы вәкил(ләр)ен) устав белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, төп һәм урта гомуми белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыруны регламентлаштыра торган башка документлар, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштыру факты;

м) балигъ булган укучының яисә балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарының) (законлы вәкил(ләр)енең) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкил(ләр)е) яки Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булган укучы гаризада өстәмә рәвештә рус телен белүгә тест узу өчен ризалык бирәләр.

2.13. Гариза һәм документлар белем бирү оешмасына шәхсән яисә, тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.

Укучы үзе белем ала торган белем бирү оешмасында укучыларны шәхси сайлап алуда катнашкан очракта, әлеге белем бирү оешмасы карамагындагы документлар тапшырылмый.

2.14. Документлар кергән көнне белем бирү оешмасы гаризаны керә торган корреспонденция журналында терки. Гаризаны шәхсән тапшырган мөрәҗәгать итүчеләргә гаризаны һәм аңа беркетелгән документлар исемлеге, алу датасы күрсәтелгән расписка бирелә.

2.15. Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкил(ләр)е) яки Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булган укучы 458 номерлы Тәртипнең $26^1$ и $26^2$ пунктлаларында күрсәтелгән документларны тапшыра(лар).

Белем бирү оешмасы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документларның дөреслеген аларны тапшырган көннән алып 25 эш көне эчендә 458 номерлы Тәртипнең $23^1$ пунктында билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

458 номерлы Тәртипнең $26^1$ һәм $26^2$ пунктларында каралган документларның дөреслеген раслаган көннән башлап, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2025 елның 4 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын үзләштерү өчен җитәрлек булган рус телен белүгә дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмасында тест үткәрү тәртибе нигезендә, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат булган укучы белем бирү оешмасы тарафыннан төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын үзләштерү өчен җитәрлек рус телен белүгә тест узу өчен дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына җибәрелә.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны да рус телендә яки билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемәсе белән тапшыралар.

2.16. Гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 2.11 һәм 2.12 пунктларында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.15 пунктының беренче абзацында каралган документларны тапшырмау (чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучы өчен);

тапшырылган документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зараланулар булу;

гаризаны әлеге Тәртиптә билгеләнгән вакытлардан тыш тапшыру.

Җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, гариза, югарыда күрсәтелгән вакыт эчендә, кабат бирелергә мөмкин.

2.17. Әлеге Тәртипнең 2.15 пунктының 2 абзацында билгеләнгән очраклардан тыш, хәбәрнамәне җибәрү фактын һәм датасын дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүчегә гаризаның һәм документларның кире кайтарылуы турында белем бирү оешмасы язма рәвештә хәбәр итә.

2.18. Шәхси сайлап алуны оештыру һәм уздыру өчен белем бирү оешмасы тарафыннан шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе төзелә, шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, апелляцияләрне карау өчен, апелляция комиссиясе төзелә.

Хокукый статус, санлы состав, чакыру тәртибе, карар кабул итү өчен кворум, вәкаләтләр, карарлар кабул итү һәм аны рәсмиләштерү тәртибе, шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе эшчәнлегенең башка үзенчәлекләре белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе белем бирү оешмасының педагогик, җитәкче һәм башка хезмәткәрләре һәм (яисә) белем бирү өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары вәкилләре, белем бирү оешмасының идарә органнары вәкилләреннән төзелә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе составына керүче затлар апелляция комиссиясе составына керә алмыйлар.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе составы, апелляция комиссиясе составы, рәисне дә кертеп, кимендә өч кешедән төзелә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе үз эшчәнлекләрен утырышлар рәвешендә алып баралар.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларда карауга чыгарылган мәсьәләләр һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә.

2.19. Укучыларны шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе утырышы беркетмәсенә түбәндәге мәгълүматлар керә:

шәхси сайлап алуда катнашкан һәр укучының суммар балын күрсәтеп, кимү тәртибендә урнашкан укучыларның рейтинг баллары;

төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул итүгә яисә күчерүгә тәкъдим ителгән укучылар исемлеге;

төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул итүдән яисә күчерүдән баш тартырга тәкъдим ителгән укучылар исемлеге.

2.20. Шәхси сайлап алу нәтиҗеләре һәм шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе беркетмәсе нигезендә, шәхси сайлап алу комиссиясенә гаризалар һәм документлар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә, белем бирү оешмасы тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча укучыны белем бирү оешмасына (сыйныфына) кабул итү яки күчерү турында;

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча укучыны белем бирү оешмасына (сыйныфына) кабул итү яки күчерүдән баш тарту турында;

Карар, укучыларга, аларның ата-анасына(ата-аналарына) (законлы вәкил(ләр)енә), белем бирү оешмасының локаль норматив актында билгеләнгән форма буенча һәм срокларда җиткерелә.

Карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә, белем бирү оешмасы җитәкчесе укырга кабул итү турында күрсәтмә акт чыгара, анда кабул итү датасы һәм сыйныф күрсәтелә.

2.21. Төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул итүдән яисә күчерүдән баш тарту өчен нигез булып төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларында буш урыннар булмау тора.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган укырга керүчеләр өчен кабул итүдән баш тартуга нигез булып, аларның Россия Федерациясе территориясендә законлы булуын раслый торган документ, шулай ук рус телен белүгә уңышлы тест нәтиҗәләре булмау тора.

2.22. Укучыны шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) кабул итүдән баш тарту, аны ул укый торган белем бирү оешмасыннан чыгаруга нигез булып тора алмый.

2.23. Белем бирү оешмасына кабул итүдән яисә күчерүдән баш тарткан очракта, балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле(ләр)е), башка гомуми белем бирү оешмасына урнашу мәсьәләсен хәл итү өчен, турыдан-туры Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына яисә белем бирү өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәләр.

2.24. Укучы төп гомуми белем алу өчен белем бирү оешмасындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына кабул ителгән очракта, тапшырылган документларның күчермәләре укучының шәхси эшендә саклана.

## III. Апелляцияләрне кабул итү һәм аларны карау

3.1. Шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле(ләр)е) апелляция комиссиясенә апелляция бирә ала. Апелляция комиссиясенә шәхси сайлап алу нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча апелляция бирелә.

Апелляция комиссиясенә апелляция бирү тәртибе, эш регламенты һәм апелляция комиссиясе составы белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнә.

3.2. Апелляция комиссиясе составы, шәхси сайлап алуны уздыруда катнашмаган белем бирү оешмасы хезмәткәрләре арасыннан, кимендә өч кешедән төзелә.

Апелляция комиссиясе утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

3.3. Балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкиле(ләр)е апелляцияне караганда анда катнашырга хокуклы.

3.4. Апелляция биргән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча апелляция комиссиясе бирелгән апелляцияне карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне кире кагу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм шәхси сайлап алу нәтиҗәләрен үзгәртү турында.

3.5. Апелляция комиссиясе карары апелляция биргән балигъ булган укучыга, балигъ булмаган укучының ата-анасына (ата-аналарына) (законлы вәкил(ләр)енә) җиткерелә һәм белем бирү оешмасы җитәкчесенә карар кабул ителгән көнне тапшырыла.

3.6. Апелляция комиссиясе апелляцияне канәгатьләндерү һәм шәхси сайлап алу нәтиҗәләре үзгәрү турында карар кабул иткән очракта, белем бирү оешмасы апелляция комиссиясенең әлеге карарын алган көннән соң бер эш көне эчендә шәхси сайлап алу нәтиҗәсен үзгәртү турында карар кабул итә.

## IV. Белем бирү оешмасына кабул итү

4.1. Бер белем бирү оешмасы эчендә төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) шәхси сайлап алуны уңышлы узган укучыларны кабул итү, белем бирү оешмасының локаль актларында билгеләнгән тәртиптә, укырга кабул итү турындагы күрсәтмә акт нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Төп гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) шәхси сайлап алуны уңышлы узган укучыларны башка белем бирү оешмасына кабул итү, укучының ата-аналарының (законлы вәкилләренең) кабул итү турындагы гаризасы һәм 458 нче Тәртипнең 26 пунктындагы документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
02.02.2026
№ под-149/26
боерыгы белән расланды

# Урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә укучыларны шәхси сайлап алуны оештыру Тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип, урта гомуми белем алу өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларындагы (алга таба – белем бирү оешмасы (оешмалары) аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү (профильле укыту) сыйныфларына кабул иткәндә яки күчергәндә, укучыларны шәхси сайлап алуны (алга таба – шәхси сайлап алу) оештыруны җайга сайла.

1.2. Шәхси сайлап алу түбәндәге очракларда үткәрелә:

урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче яки төп гомуми белем бирү программасын үзләштерүне тәмамлаган укучыларны аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яисә профильле укыту сыйныфларына кабул иткәндә;

балигъ булмаган укучыларны, хәрби яки башка дәүләт хезмәтенә әзерләү максаты белән «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган өстәмә гомуми белем бирү программалары белән интеграцияләнгән белем бирү программалары буенча укытуны да кертеп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт белем бирү оешмаларына кабул иткәндә.

1.3. Шәхси сайлап алганда, белем бирү оешмалары, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гражданнарның белем алуга хокукларын үтәргә, кабул итү комиссияләре эшендә хәбәрдарлык һәм ачыклык шартларын булдырырга, укучыларның сәләтен һәм хирыслыгын бәяләүнең объективлыгын тәэмин итәргә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә субъектларның шәхси мәгълүмат хокукларын үтәргә тиеш.

1.4. Урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә барлык фәннәр дә база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфлар яки универсаль профильле сыйныфлар, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле укыту сыйныфлары ачу һәм аларның тулыланышы турында карар (күрсәтмә акт) белем бирү оешмасы һәм белем бирү өлкәсендә идарә итә торган гамәлгә куючысы белән үзара килешеп кабул ителә. Бу карар, агымдагы уку елының 1 мартыннан да соңга калмыйча кабул ителә һәм 10

календарь көненнән дә соңга калмыйча, белем бирү оешмасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, белем бирү оешмасының мәгълүмат стендларында урнаштырыла. Укучыларга һәм балигъ булмаган укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә), әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш, башка ысуллар белән җиткерелә.

Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле укыту сыйныфлары белем бирү оешмасы мөмкинлекләрен, укучыларның, балигъ булмаган укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) мәнфәгатьләрен һәм белем алу ихтыяҗларын исәпкә алып ачыла.

Урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы югары белем бирү оешмаларында аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яки профильле укыту сыйныфлары ачу турында карар, югары белем бирә торган тиешле белем бирү оешмалары тарафыннан, законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

## II. Шәхси сайлап алу тәртибе

2.1. Төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүне тәмамлаган һәм төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен (алга таба – ДЙА) узган укучылар өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү яисә профильле укыту сыйныфларына шәхси сайлап алуны оештыру белем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, әлеге Тәртип һәм белем бирү оешмасының локаль норматив акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Гаризаларны тапшыру сроклары, вакыты, урыны һәм укучыларны шәхси сайлап алу сроклары һәм процедурасы, аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерү нигезендә өйрәнелә торган фәннәр һәм профильле укыту турында мәгълүмат, белем бирү оешмасының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, белем бирү оешмасының мәгълүмат стендларында урнаштырыла һәм укучыларга, балигъ булмаган укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) шәхси сайлап алу башланырга 45 көннән дә соңга калмый башка ысуллар белән җиткерелә.

2.3. Шәхси сайлап алу үткәрелә:

1 июльдән 20 августка кадәр (буш урыннар булганда – 31 августка кадәр) урта гомуми белем һәм профильле белем алу өчен кабул иткәндә яисә күчергәндә (урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә барлык фәннәр дә база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфлар яки универсаль профильле сыйныфлардан тыш), белем бирү оешмасы укучыны яңа уку елының 1 сентябреннән 10 сыйныфка кабул итә;

календарь елының 1 июленнән 20 августына кадәр (буш урыннар булганда – 31 августка кадәр) урта гомуми белем алу өчен «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамасы булган дәүләт белем бирү оешмасына кабул

иткәндә, дәүләт гомуми белем бирү оешмасы укучыны яңа уку елының 1 сентябреннән үзенә кабул итә.

Әгәр шәхси сайлап алуның беренче көне эш көне булмаган көнгә туры килсә, шәхси сайлап алуның башлану көне дип аннан соңгы эш көне санала.

Шулай ук, урта гомуми белем алу өчен укучыларны шәхси сайлап алу уку елы дәвамында да аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү һәм профильле укыту сыйныфларында буш урыннар булганда (барлыкка килгәндә) үткәрелә.

Урта гомуми белем бирү программасын үзләштерү вакыты кысаларында «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган бер дәүләт гомуми белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчергәндә шәхси сайлап алу уздырылмый.

2.4. Шәхси сайлап алуда катнашу турында гаризаны карау срогы – гариза тапшырылган көннән алып 30 календарь көнен тәшкил итә.

2.5. Укучыларны шәхси сайлап алу, аларның урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программасын үзләштерүгә ирешкән казанышларын исәпкә алып, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүгә һәм профильле укытуга сәләтләрен бәяләү нигезендә, әлеге Тәртиптә билгеләнгән система һәм укучыларның аерым уку предметларын өйрәнүгә сәләтләрен бәяләү критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Профильле укыту (табигый-фәнни, агротехнологик, гуманитар, социаль-икътисадый, технологик профильле) сыйныфларына белем бирү оешмалары, төп гомуми белем турында аттестат алу өчен җитәрлек беренчел баллларның минималь саны булган нәтиҗәләр булганда, укучыларны индивидуаль сайлап алуны гамәлгә ашыралар. Аттестат, укучыларның агымдагы елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләре нигезендә төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүен раслый:

а) ДЙАның дүрт фәне буенча:

ике мәҗбүри фән (“Рус теле” һәм “Математика", алга таба – мәҗбүри фәннәр);

белем бирү профилен исәпкә алып, ДЙА фәннәре арасыннан, укучы сайлап алган ике фән («Физика», «Химия», «Биология», «География», «Информатика», «Чит телләр» (инглиз, испан, немец һәм француз телләре), «Тарих», «Әдәбият», «Җәмгыять белеме», алга таба – сайлап алу фәннәре):

| Укыту профиле | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Технологик | Табигый-фәнни | Агротехнологик | Гуманитар | Социаль-икътисадый |
| физика, информатика, химия | физика, химия, биология, информатика | физика, химия, биология, география, информатика | тарих, җәмгыять белеме, чит телләр, әдәбият, туган тел | тарих, җәмгыять белеме, география |

б) ДЙАны ике мәҗбүри фән буенча гына узган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, инвалид балалар һәм инвалидлар өчен.

Түбәндәге формула буенча, укучылар рейтингы баллар суммасын санау юлы белән формалаштырыла:

Р балл= К1+К2+К3:

К1- ДЙА нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән күрсәткечтән кимрәк булмаган һәр фән буенча беренчел баллар суммасы;

К2- әлеге Тәртипнең 2.7 пунктында күрсәтелгән укучыларның шәхси казанышлары өчен өстәмә баллар суммасы. Сайлап алу фәннәренең нәтиҗәләре булганда, күрсәтелгән укучылар ДЙАның нәтиҗәләрен тапшырырга хокуклы;

К3- ике керү сынавы нәтиҗәләре буенча уртача балл (алар уздырылган очракта).

Белем бирү оешмасы, профильле укыту сыйныфларына шәхси сайлап алуны уздырганда, өстәмә рәвештә икедән артык булмаган бәяләү эшләре (яисә бер бәяләү эше һәм әңгәмә) формасында укырга керү сынавын оештырырга мөмкин.

Бәяләү эшләренең, шулай ук әңгәмәләрнең формасы һәм эчтәлеге, аларны үткәрү тәртибе һәм шәхси сайлап алуны уздырганда нәтиҗәләрне исәпкә алу белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнә.

2.6.1. Универсаль профильле сыйныфларга яки урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә барлык фәннәр база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфларга, белем бирү оешмалары, укучыларны түбәндәге нәтиҗәләр булганда шәхси сайлап ала:

төп гомуми белем турында аттестат алу өчен, укучы, аттестат алу өчен җитәрлек дип билгеләнгән минималь баллар җыеп, дүрт фәннән имтиханнарны уңышлы тапшырырганда. Аттестат, укучыларның агымдагы елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләре нигезендә төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүен раслый;

әгәр сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, белем алучы инвалид балалар һәм инвалидлар ДЙАны ике мәҗбүри фәннән тапшырып, кирәкле минималь балл җыйсалар яисә билгеләренең минималь күрсәткечләре аттестат алырга җитәрлек булса, алар төп гомуми белем турында аттестат алалар. Аттестат, укучыларның агымдагы елда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләре нигезендә төп гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүен раслый.

Төп гомуми белем турында аттестатның уртача баллы югарырак булган укучылар универсаль профильле сыйныфларга яисә урта гомуми белемнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә барлык фәннәр

база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфларга керү өчен өстенлекле хокукка ия.

2.6.2. Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең норматив хокукый актлары нигезендә арадаш аттестация рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясен узу хокукына ия булган укучылар өчен профильле сыйныфларга сайлап алу нәтиҗәләре буларак исәпкә алына:

төп гомуми белем турындагы аттестатның дүрт фәне буенча билгеләр суммасы: әлеге Тәртипнең 2.6 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән ике мәҗбүри фәннән һәм ДЙА фәннәре арасыннан, укучы сайлап алган ике фәннән;

әлеге Тәртипнең 2.7 пунктында күрсәтелгән укучыларның индивидуаль казанышлары өчен өстәмә баллар суммасы (булган очракта);

ике укырга керү сынавы нәтиҗәләре буенча уртача балл (алар уздырылган очракта).

2.7. Урта гомуми белем алу өчен белем бирү оешмаларының профильле укыту сыйныфларына (универсаль профильдән яисә барлык фәннәр урта гомуми белемнең федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре нигезендә база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфлардан тыш) кабул иткәндә яки күчергәндә өстәмә баллар бирелә:

тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында укучыларның бөтенроссия олимпиадасының аерым этапларында катнашу нәтиҗәсе;

укучыларның тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясенең Фән һәм югары белем министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларда, чараларда яуланган призлы урыннары.

Өстәмә баллар суммасы түбәндәге критерийлар нигезендә баллар суммасы буларак билгеләнә.

Укучыларның шәхси казанышлары өчен өстәмә баллар

| Күрсәт-кеч | Олимпиада-ның мәктәп этабы (баллар саны) | Олимпиаданың муниципаль этабы (баллар саны) | Олимпиаданың, башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларның, чараларның төбәк/сайлап алу этабы (баллар саны) | Олимпиаданың, башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларның, чараларның йомгаклау этабы (баллар саны) |
|---|---|---|---|---|
| К1 | 1 балл (нинди дә булса статус) | 2 балл (призер статусы)<br>3 балл (җиңүче статусы) | 3 балл (призер статусы)<br>4 балл (җиңүче статусы) | 4 балл (призер статусы)<br>5 балл (җиңүче статусы) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| К2 | 1 балл (призер статусы) 2 балл (җиңүче статусы) | 4 балл (призер статусы) 6 балл (җиңүче статусы) | 6 балл (призер статусы) 8 балл (җиңүче статусы) | 8 балл (призер статусы) 10 балл (җиңүче статусы) |
| К3 | | | 6 балл (призер статусы) 7 балл (җиңүче статусы) | 12 балл (призер статусы) 13 балл (җиңүче статусы) |
| К4 | | | 12 балл (призер статусы) 13 балл (җиңүче статусы) | 24 балл (призер статусы) 25 балл (җиңүче статусы) |

К1- тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында профильле укыту яки тирәнтен өйрәнүле фәннәрдән тыш, укучыларның бөтенроссия олимпиадасында яулаган призлы урыннары;

К2- тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында профильле уку яки тирәнтен өйрәнүле фәннәр буенча, укучыларның бөтенроссия олимпиадасында яулаган призлы урыннары;

К3- исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясенең Фән һәм югары белем министрлыгы боерыгы белән расланган, профильле укыту яки тирәнтен өйрәнүле фәннәрдән тыш, укучыларның олимпиадада яулаган призлы урыннары;

К4- тиешле белем бирү дәрәҗәсе буенча укыган елларында, исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган, профильле укыту яки тирәнтен өйрәнүле фәннәр буенча укучыларның олимпиадаларда һәм башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурсларда, чараларда яуланган призлы урыннары.

2.8. Укучыларны шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча профильле укыту сыйныфларына кабул итү яки күчерү хокукына, һәр катнашучының җыйган суммар баллын кимү тәртибендә күрсәтеп, иң югары рейтинглы укучылар ия була.

Шәхси сайлап алуны оештырганда укырга керү сынауларын инди дә булса башка формада уздыру рөхсәт ителми.

2.9. Укучыларның түбәндәге категорияләре, шәхси сайлап алуның нәтиҗәләре тигез булган очракта, профильле укыту яки аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына кабул ителгәндә өстенлекле кабул ителү хокукына ия:

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы (алга таба - 458 номерлы Тәртип) белән расланган башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү Тәртибендә билгеләнгән хокукка ия укучылар;

төп гомуми белем турында аттестатның уртача баллы югарырак булган укучылар;

белем бирү оешмаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен белем алуның кирәкле махсус шартлары булган очракта, психолог-медицина-педагогик комиссия һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәләре нигезендә тиешле мәгариф оешмаларында белем алуга каршы килүләре булмаган сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар, инвалид балалар һәм инвалидлар;

күрсәтелгән белем бирү оешмасына беркетелгән территориядә яшәүче укучылар;

федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардагы башка затлар.

2.10. Укучыларның түбәндәге категорияләре, шәхси сайлап алуның нәтиҗәләре тигез булган очракта, «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына кабул иткәндә өстенлекле кабул итү хокукына ия:

458 нче Тәртиптә билгеләнгән әлеге хокукка ия булган укучылар;

махсус хәрби операция яисә террорчылыкка каршы операция уздырыла торган районнардан эвакуацияләнгән балалар;

федераль законнарда яисә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардагы башка затлар.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 86 маддәсенең $6^1$ өлешендә күрсәтелгән балаларны «кадет мәктәбе», «кадет корпусы» махсус атамалары булган дәүләт гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү укырга керү сынауларысыз һәм рейтинг балларын анализламыйча гамәлгә ашырыла.

2.11. Белем бирү оешмасы үзенең сайтында һәм мәгълүмат стендында локаль норматив актта билгеләнгән срокта шәхси сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштыра, ул түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

шәхси сайлап алуны уздыру сроклары;

гаризаларны кабул итә башлау һәм аларны кабул итүнең тәмамлану датасы, вакыты;

гаризаларны кабул итү урыны;

гариза тапшыру формасы һәм ысуллары;

шәхси сайлап алуда катнашу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

тирәнтен укыту оештырыла торган фәннәр;

шәхси сайлап алуны уздыру формалары һәм шәхси сайлап алу критерийлары;

укучыларга, ата-ана(лар)га (законлы вәкил(ләр)гә) шәхси сайлап алу йомгаклары турында мәгълүмат бирү формалары, сроклары һәм ысуллары;

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта апелляцияләр бирү тәртибе һәм сроклары.

2.12. Шәхси сайлап алуда катнашыр өчен балигъ булмаган укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), балигъ булган укучылар (алга таба –

мөрәҗәгать итүчеләр) агымдагы елның 1 июлен дә кертеп белем бирү оешмасына гариза тапшыралар һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2023 елның 6 апрелендәге 240 номерлы боерыгы белән расланган тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны башка оешмаларга күчерүне гамәлгә ашыру Тәртибе һәм шартларында билгеләнгән яки 458 Тәртиптә билгеләнгән документларга өстәп түбәндәге документларны тапшыралар:

төп гомуми белем турында аттестат;

агымдагы елда төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү оешмасы тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә торган үрнәк буенча бирелгән дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре турында белешмә (белешмәдә укучының барлык имтихан бирелә торган фәннәрдән беренчел баллары күрсәтелә: 4 фән буенча баллары һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, укучы инвалид балалар, инвалидлар өчен 2 мәҗбүри фән буенча баллары (әгәр әлеге укучылар аларны гына тапшырган булсалар));

бөтенроссия укучылар олимпиадасының барлык этапларында җиңүче һәм (яисә) призер грамоталары, дипломнары күчермәләре (булган очракта);

исемлеге һәм дәрәҗәләре Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган укучылар олимпиадаларының сайлап алу һәм (яисә) йомгаклау этапларында җиңүче һәм (яисә) призер грамоталары, дипломнары, сертификатлары, таныклыклары күчермәләре;

әлеге Тәртипнең 2.9 һәм 2.10 пунктларында күрсәтелгән белем бирү оешмасына кабул иткәндә өстенлек хокукы булуын раслаучы документларның күчермәләре (булган очракта).

Әгәр шәхси сайлап алуда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогының соңгы көне ял көненә туры килсә, срок тәмамлану көне дип алдагы эш көне санала.

2.13. Гаризаны балигъ булган укучылар яисә балигъ булмаган укучыларның ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкил(ләр)е) белем бирү оешмасының локаль норматив актында билгеләнгән форма буенча һәм срокларда тапшыралар.

Гаризада түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) укучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

б) укучының туу датасы;

в) укучының яшәү урыны адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;

г) балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарның) (законлы вәкил(ләр)енең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

д) балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарның) (законлы вәкил(ләр)енең) яшәү урынының адресы һәм (яисә) тору урынының адресы;

е) балигъ булган укучының яисә балигъ булмаган укучының ата-анасының (ата-аналарының) (законлы вәкил(ләр)енең) электрон почтасы адрес(лар)ы (булган очракта), телефон номер(лар)ы (булган очракта);

ж) әлеге Тәртипнең 2.9 һәм 2.10 пунктларында күрсәтелгән белем бирү оешмасына кабул иткәндә өстенлек хокукы булу;

з) белем бирү теле (Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телдә яисә чит телдә белем алган очракта);

и) Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган тел (Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне, шул исәптән туган тел буларак рус телен өйрәнүгә хокукны гамәлгә ашырган очракта);

к) Россия Федерациясе территориясенә керүче республиканың дәүләт теле (белем бирү оешмасы тарафыннан Россия Федерациясе территориясенә керүче республиканың дәүләт телен өйрәнү мөмкинлеге бирелгән очракта);

л) балигъ булган укучыны, балигъ булмаган укучының ата-анасын (ата-аналарын) (законлы вәкил(ләр)ен) устав белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, урта гомуми белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыруны гамәлгә ашыруны регламентлаштыра торган башка документлар, белем алучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштыру факты;

м) балигъ булган укучының яисә балигъ булмаган укучының ата-анасың (ата-аналарының) (законлы вәкил(ләр)енең) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучының ата-анасы (законлы вәкил(ләр)е) яки Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булган укучы гаризада өстәмә рәвештә рус телен белүгә тест узу өчен ризалык бирәләр.

2.14. Гариза һәм документлар белем бирү оешмасына шәхсән яисә, тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.

Укучы үзе белем ала торган белем бирү оешмасында укучыларны шәхси сайлап алуда катнашкан очракта, әлеге белем бирү оешмасы карамагындагы документлар тапшырылмый.

2.15. Документлар кергән көнне белем бирү оешмасы гаризаны керә торган корреспонденция журналында терки. Гаризаны шәхсән тапшырган мөрәҗәгать итүчеләргә гаризаны һәм аңа беркетелгән документлар исемлеге, алу датасы күрсәтелгән расписка бирелә.

2.16. Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) (законлы вәкил(ләр)е) яки Россия Федерациясенең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү

оешмаларында элек белем алмаган чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булган укучы 458 номерлы Тәртипнең $26^{1}$ и $26^{2}$ пунктлаларында күрсәтелгән документларны тапшыра(лар).

Белем бирү оешмасы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документларның дөреслеген аларны тапшырган көннән алып 25 эш көне эчендә 458 номерлы Тәртипнең $23^{1}$ пунктында билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

458 нче Тәртиптәге $23^{1}$ пунктының тугызынчы абзацында билгеләнгән очраклардан тыш, 458 номерлы Тәртипнең $26^{1}$ һәм $26^{2}$ пунктларында каралган документларның дөреслеген раслаган көннән башлап, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2025 елның 4 мартындагы 170 номерлы боерыгы белән расланган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын үзләштерү өчен җитәрлек булган рус телен белүгә дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмасында тест үткәрү Тәртибе нигезендә, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат булган укучы белем бирү оешмасы тарафыннан төп гомуми һәм урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын үзләштерү өчен җитәрлек рус телен белүгә тест узу өчен дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына җибәрелә.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар барлык документларны да рус телендә яки билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемәсе белән тапшыралар.

2.17. Гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 2.12 һәм 2.13 пунктларында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.16 пунктының беренче абзацында каралган документларны тапшырмау (чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган балигъ булмаган укучы өчен);

тапшырылган документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган зараланулар булу;

гаризаны әлеге Тәртиптә билгеләнгән вакытлардан тыш бирү.

Җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, гариза, югарыда күрсәтелгән вакыт эчендә, кабат бирелергә мөмкин.

2.18. Хәбәрнамәне җибәрү фактын һәм датасын дөрес билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүчегә гаризаның һәм документларның кире кайтарылуы турында белем бирү оешмасы язма рәвештә хәбәр итә.

2.19. Шәхси сайлап алуны оештыру һәм уздыру өчен белем бирү оешмасы тарафыннан шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе төзелә, шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, апелляцияләрне карау өчен, апелляция комиссиясе төзелә.

Хокукый статус, санлы состав, чакыру тәртибе, карар кабул итү өчен кворум, вәкаләтләр, карарлар кабул итү һәм аны рәсмиләштерү тәртибе, шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе

эшчәнлегенең башка үзенчәлекләре белем бирү оешмасының локаль норматив актлары белән билгеләнә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе белем бирү оешмасының педагогик, җитәкче һәм башка хезмәткәрләре һәм (яисә) белем бирү өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары вәкилләре, белем бирү оешмасының идарә органнары вәкилләреннән төзелә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе составына керүче затлар апелляция комиссиясе составына керә алмыйлар.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе составы, апелляция комиссиясе составы, рәисне дә кертеп, кимендә өч кешедән төзелә.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе үз эшчәнлекләрен утырышлар рәвешендә алып баралар.

Шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе һәм апелляция комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларда карауга чыгарылган мәсьәләләр һәм алар буенча кабул ителгән карарлар теркәлә.

2.20. Укучыларны шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе утырышы беркетмәсенә түбәндәге мәгълүматлар керә:

шәхси сайлап алуда катнашкан һәр укучының суммар балын күрсәтеп, кимү тәртибендә урнашкан укучыларның рейтинг баллары;

урта гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул итүгә яисә күчерүгә тәкъдим ителгән укучылар исемлеге;

урта гомуми белем алу өчен аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфларына кабул итүдән яисә күчерүдән баш тартырга тәкъдим ителгән укучылар исемлеге.

2.21. Шәхси сайлап алу нәтиҗеләре һәм шәхси сайлап алу буенча кабул итү комиссиясе беркетмәсе нигезендә, шәхси сайлап алу комиссиясенә гаризалар һәм документлар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә, белем бирү оешмасы тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча укучыны белем бирү оешмасына (сыйныфына) кабул итү яки күчерү турында;

шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча укучыны белем бирү оешмасына (сыйныфына) кабул итү яки күчерүдән баш тарту турында;

Карар, укучыларга, аларның ата-анасына(ата-аналарына) (законлы вәкил(ләр)енә), белем бирү оешмасының локаль норматив актында билгеләнгән форма буенча һәм срокларда җиткерелә.

Белем бирү оешмасы җитәкчесе карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә укырга кабул итү турында күрсәтмә акт чыгара, анда кабул итү датасы һәм сыйныф күрсәтелә.

2.22. Урта гомуми белем алу өчен профильле укыту сыйныфларына яки аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) кабул итүдән яисә күчерүдән баш тарту өчен нигез булып буш урыннар булмау тора.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган укырга керүчеләр өчен кабул итүдән баш тартуга нигез булып аларның Россия Федерациясе территориясендә законлы булуын раслый торган документ, шулай ук рус телен белүгә уңышлы тест нәтиҗәләре булмау тора.

2.23. Укучыны шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча профильле укыту сыйныфларына яки аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) кабул итүдән баш тарту, аны ул элек төп гомуми белем алган белем бирү оешмасындагы универсаль профильле сыйныфларга яки урта гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә барлык предметлар да база дәрәҗәсендә өйрәнелә торган сыйныфларга кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.24. Белем бирү оешмасына кабул итүдән яисә күчерүдән баш тарткан очракта, балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) законлы вәкил(ләр)е), башка гомуми белем бирү оешмасына урнашу мәсьәләсен хәл итү өчен, турыдан-туры Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына яисә белем бирү өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итәләр.

2.25. Укучы урта гомуми белем алу өчен белем бирү оешмасындагы профильле укыту сыйныфларына яки аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) кабул ителгән очракта, тапшырылган документларның күчермәләре укучының шәхси эшендә саклана.

## III. Апелляцияләрне кабул итү һәм аларны карау

3.1. Шәхси сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) законлы вәкил(ләр)е) апелляция комиссиясенә апелляция бирә ала.

3.2. Апелляция комиссиясенә гариза тапшыру тәртибе, эш регламенты һәм апелляция комиссиясе составы белем бирү оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнә.

Апелляция комиссиясе составы, шәхси сайлап алуны уздыруда катнашмаган белем бирү оешмасы хезмәткәрләре арасыннан, кимендә өч кешедән төзелә.

Апелляция комиссиясе утырышында аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

Апелляция комиссиясенә шәхси сайлап алу нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча апелляция бирелә.

3.3. Балигъ булган укучы, балигъ булмаган укучының ата-анасы (ата-аналары) законлы вәкил(ләр)е апелляцияне караганда анда катнашырга хокуклы.

3.4. Апелляция биргән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча апелляция комиссиясе бирелгән апелляцияне карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне кире кагу турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм шәхси сайлап алу нәтиҗәләрен үзгәртү турында.

3.5. Апелляция комиссиясе карары апелляция биргән балигъ булган укучыга, балигъ булмаган укучының ата-анасына (ата-аналарына) законлы вәкиле(ләр)енә җиткерелә һәм белем бирү оешмасы җитәкчесенә карар кабул ителгән көнне тапшырыла.

3.6. Апелляция комиссиясе апелляцияне канәгатьләндерү һәм шәхси сайлап алу нәтиҗәләре үзгәрү турында карар кабул иткән очракта, белем бирү оешмасы апелляция комиссиясенең әлеге карарын алган көннән соң бер эш көне эчендә шәхси сайлап алу нәтиҗәсен үзгәртү турында карар кабул итә.

## IV. Белем бирү оешмасына кабул итү

4.1. Бер белем бирү оешмасы эчендә урта гомуми белем алу өчен профильле сыйныфларга яки аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) шәхси сайлап алуны уңышлы узган укучыларны кабул итү, белем бирү оешмасының локаль актларында билгеләнгән тәртиптә, укырга кабул итү турындагы күрсәтмә акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Урта гомуми белем алу өчен профильле сыйныфларга яки аерым уку фәннәрен тирәнтен өйрәнү сыйныфына (сыйныфларына) шәхси сайлап алуны уңышлы узган укучыларны башка белем бирү оешмасына кабул итү, укучының ата-аналарының (законлы вәкилләренең) яисә балигъ булган укучының кабул итү турындагы гаризасы һәм 458 нче Тәртипнең 26 пунктындагы документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.